ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

09.08.2019 с. Большие Кайбицы № 363

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы мәгариф оешмаларында эшләүче педагогик хезмәткәрләр-яшь белгечләргә Татарстан Республикасы бюджеты чараларыннан бирелә торган чаралар хисабына айлык стимуллаштыру өстәмә түләвен бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018елның 29 декабрендә чыккан 1270номерлы «Педагогик хезмәткәрләр- яшь белгечләргә айлык стимуллаштыру өстәмә түләве билгеләү турында» карары нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР КЫЛА:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы мәгариф оешмаларында эшләүче педагогик хезмәткәрләр- яшь белгечләргә Татарстан Республикасы бюджеты чараларыннан бирелә торган чаралар хисабына айлык стимуллаштыру өстәмә түләвен бирү тәртибен расларга (кушымта №1).

2. Бу карар 2019 елның 1 гыйнварыннан чыккан хокук мөнәсәбәтләренә тарала дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының информацион-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге http:// kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Башкарма комитет Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.А.Биккуловага йөкләргә.

Җитәкче А.Н. Макаров

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитетының
2019е. 9 августындагы 363 номерлы
карарына Кушымта №1

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы мәгариф оешмаларында эшләүче педагогик хезмәткәрләр-яшь белгечләргә Татарстан Республикасы бюджеты чараларыннан бирелә торган чаралар хисабына айлык стимуллаштыру өстәмә түләвен бирү
Тәртибе

1.Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы мәгариф оешмаларында эшләүче педагогик хезмәткәрләр-яшь белгечләргә айлык стимуллаштыру өстәмә түләү күләмен һәм тәртибен билгели, аларга карата оештыручы функцияләре һәм вәкаләтләре Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән Министрлыгы (алга таба - Оешма) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2. Педагогик хезмәткәрләр-яшь белгечләргә түләү Татарстан Республикасы бюджетында агымдагы финанс елына Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән Министрлыгы өчен 1 пунктта күрсәтелгән максатта түләү өчен карала.

3. Әлеге Тәртиптә педагогик хезмәткәр-яшь белгеч дип беренче тапкыр көндезге формада һөнәри мәгариф оешмасын яки югары белем мәгариф программалары - бакалавриат, специалитет, магистратура, аспирантура буенча дәүләт аккредитациясе булган югары белем мәгариф оешмасын тәмамлаган һәм Оешмага һөнәри белем дәрәҗәсе һәм квалификациясе буенча укуын тәмамлаган елның 1 ноябреннән дә соңга калмыйча эшкә хезмәт килешүе белән алынган 30 яшькә кадәрге зат санала.

4. Педагогик хезмәткәрләр-яшь белгечләргә өстәмә стимуллаштыру түләве билгеләү хокукы түбәндәге оешмаларда каралган:

мәктәпкәчә белем оешмалары;
гомуми белем оешмалары;
өстәмә белем оешмалары.

5. Педагогик хезмәткәрләр-яшь белгечләргә өстәмә айлык стимуллаштыру түләве эшкә урнашу көненнән алып беренче өч ел дәвамында педагогик вазыйфада туктаусыз хезмәт өчен билгеләнә.

Педагогик хезмәткәрләр-яшь белгечләргә өстәмә айлык стимуллаштыру түләвен билгеләү, туктату, озынайту турында карар Оешма приказы белән билгеләнә.

6. Айлык стимуллаштыру өстәмә түләвен алу өчен әлеге Тәртипнең 3 пункты белән билгеләнгән эшкә урнашу срогын игътибарга лаек сәбәпләр буенча кичектерүгә түбәндәгеләр керә:

документаль рәвештә расланган вакытлыча эшкә яраксыз булу;

Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә чакыру буенча хезмәт үтү яки альтернатив гражданлык хезмәте үтү;

йөклелек һәм бала табу буенча ял, балага өч яшь тулганчы аны карау буенча ял.

Айлык стимуллаштыру өстәмә түләве педагогик хезмәткәр-яшь белгечкә хезмәт мөнәсәбәтләрен вакытлыча эшкә яраксыз булу, Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә чакыру буенча хезмәт үтү яки альтернатив гражданлык хезмәте үтү, йөклелек һәм бала табу буенча ял, балага өч яшь тулганчы аны карау буенча ял тәмамланганнан соң 60 көннән дә соңга калмыйча рәсмиләштерсә билгеләнергә мөмкин.

7. Хезмәт килешүе хезмәткәр хәрби хезмәткә яки аны алыштыручы альтернатив хезмәткә чакырылу сәбәпле туктаталса, айлык стимуллаштыру өстәмә түләве хезмәткәр Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә чакыру буенча хезмәт үтү яки альтернатив гражданлык хезмәте үтү вакыты тәмамланганнан соң 60 көннән дә соңга калмыйча рәсмиләштерсә билгеләнергә мөмкин.

8. Оешма белән хезмәт мөнәсәбәтләрендә торучы педагогик хезмәткәр-яшь белгечкә айлык стимуллаштыру өстәмә түләве түбәндәге чорларга туктатылып тора:

йөклелек һәм бала табу буенча ял, балага өч яшь тулганчы аны карау буенча ял;

аспирантурада көндезге формада уку.

9. Башка Оешмага педагогик вазыйфага күчкән очракта хезмәттә 30 көннән дә артмаган тәнәфес рөхсәт ителә.

10. Педагогик хезмәткәр-яшь белгечнең штатны кыскарту сәбәпле эштән китүе очрагында алга таба педагогик вазыйфага эшкә урнашканда 60 көннән дә артмаган тәнәфес рөхсәт ителә.

11. Педагогик хезмәткәр-яшь белгечләргә айлык стимуллаштыру өстәмә түләве педагогик хезмәткәрләр вазыйфалары буенча белем бирү эшчәнлеге башкаручы оешма педагогик хезмәткәрләре вазыйфалары, белем бирү оешмалары җитәкчеләре вазыйфалары номенклатурасының (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013елның 8 августында чыккан 678 номерлы «Белем бирү эшчәнлеге башкаручы оешма педагогик хезмәткәрләре вазыйфалары, белем бирү оешмалары җитәкчеләре вазыйфалары номенклатурасын раслау турында» карары нигезендә расланган) 1 бүлеге 2 пункты нигезендә билгеләнә.

12. Педагогик хезмәткәр-яшь белгечләргә айлык стимуллаштыру өстәмә түләве педагогик хезмәткәр-яшь белгечнең төп эш урыны буенча гына билгеләнә.

13. Педагогик хезмәткәр-яшь белгечләргә айлык стимуллаштыру өстәмә түләве төп педагогик эшчәнлеге буенча һәм әлеге педагогик хезмәткәр-яшь белгеч эчке берләштерү шартларында башкара торган эш өчен түләнә.

14. Педагогик хезмәткәр-яшь белгечләргә айлык стимуллаштыру өстәмә түләве күләме әлеге формула буенча исәпләнә:

$D = P \times Hf / Hn$,

монда:

D - педагогик хезмәткәр-яшь белгечләргә, атнага педагогик эшчәнлек сәгатьләре нормасы билгеләнгән, аена 1 111 сумнан да артык булмаган айлык стимуллаштыру өстәмә түләве күләме;

P - педагогик хезмәткәр-яшь белгечләргә, атнага педагогик эшчәнлек сәгатьләре нормасы өчен 1 111 сум күләмендәге стимуллаштыру өстәмә түләве;

Hf –педагогик эшчәнлек алып баруның факттагы сәгатьләр саны;

Hn - хезмәт хакы база ставкасы өчен сәгатьләр нормасы.

15. Педагогик хезмәткәр-яшь белгечләргә айлык стимуллаштыру өстәмә түләве күләме (әлеге Тәртипнең 12 пункты белән айлык стимуллаштыру өстәмә түләве билгеләнгән педагогик хезмәткәр-яшь белгечләрдән кала) әлеге формула буенча исәпләнә:

D = P x t,

монда:

D - педагогик хезмәткәр-яшь белгечләргә айлык стимуллаштыру өстәмә түләве күләме, ләкин айга 1 111 сумнан артык түгел;

P - педагогик хезмәткәр-яшь белгечләргә хезмәт хакы ставкасына 1 111 сум күләмендә айлык стимуллаштыру өстәмә түләве;

t – фактта эшләнгән вакыт (ставка).

16. Педагогик хезмәткәрләргә айлык стимуллаштыру түләве Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган субсидия акчалары хисабыннан түләнә.

17. Оешма Тармак министрлыкларына түбәндәге документларны тапшыра:

Тармак министрлыклары раслаган форма буенча айлык стимуллаштыру түләве өчен субсидия бирүгә гариза;

буенча айлык стимуллаштыру түләве өчен субсидия бирү гаризасын имзалаган зат вәкаләтләрен раслаучы документ;

Тармак министрлыклары приказлары белән расланган форма буенча педагогик хезмәткәр-яшь белгечләр реестры.

18. Тармак министрлыклары әлеге Тәртипнең 16 пунктында күрсәтелгән документларны кергәннән соң 10 эш көнендә карый.

Оешма тарафыннан әлеге Тәртипнең 16 пунктында күрсәтелгән документларның тулы пакеты җбирелмәсә, яки әлеге Тәртипнең 16 пунктында күрсәтелгән таләпләр үтәлмәсә, Тармак министрлыклары документларны кире кайтара һәм 5 көн эчендә Оешмага сәбәпләрен күрсәтеп, документлар пакетын кайтару турында хәбәр итә.

Оешма документлар пакетын кайтару турында хәбәр алган көннән әлеге Тәртипнең 16 пунктында күрсәтелгән документларны, әлеге Тәртиптә күрсәтелгән таләпләр үтәлгән очракта, кабат тапшыра.

19. Педагогик хезмәткәрләргә айлык стимуллаштыру түләве өчен субсидияләр Татарстан Республикасы бюджетыннан педагогик хезмәткәрләргә айлык стимуллаштыру түләве өчен субсидияләр бирү турында килешү (алга таба - Килешү) нигезендә бирелә. Килешү Тармак министрлыгы һәм Оешма арасында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә төзелә.

Килешү Тәртипнең 16 пунктында күрсәтелгән таләпләргә җавап бирүче документлар тапшырылганнан соң 10 көн эчендә төзелә.

20. Тармак министрлыклары квартал саен Оешманың лицевой счетларына әлеге Тәртипнең 2 пунктына туры китереп, педагогик хезмәткәр-яшь белгечләргә айлык стимуллаштыру өстәмә түләве өчен субсидияләр күчерә.

21. Оешмалар Тармак министрлыкларына педагогик хезмәткәр-яшь белгечләргә айлык стимуллаштыру өстәмә түләве өчен субсидияләрне куллану турында Килешү белән каралган срокта һәм формада хисап бирә.

22. Оешма тарафыннан агымдагы финанс елында кулланылмаган субсидия калдыклары году билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиеш.

23. Оешма тарафыннан субсидияләр бирү шартлары бозылган очракта Тармак министрлыгының язмача таләбе нигезендә субсидияләр билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына күрсәтелгән таләп алынганнан соң 10 көн эчендә кире кайтарылырга тиеш.

24. Оешма тарафыннан субсидияләр бирү, шулай ук Килешү шартларын үтәүне контрольдә тоту Тармак министрлыклары һәм дәүләт финанс контроле вәкаләтле органнары тарафыннан башкарыла.

25. Оешмалар педагогик хезмәткәр-яшь белгечләргә айлык стимуллаштыру өстәмә түләвен ай саен Оешма тарафыннан билгеләнгән хезмәт хакы түләү срокларында бирүне тәэмин итә.